**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 сентябрь № 657

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының аерым дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләрен бетерү турында» 2016 ел, 8 апрель, 207 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының аерым дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләрен бетерү турында» 2016 ел, 8 апрель, 207 нче карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарга түбәндәге эчтәлекле $3^1$ нче пункт өстәргә:

«Ябыла торган «2 нче республика клиник хастаханәсе», Казан шәһәренең «2 нче ашыгыч медицина ярдәме шәһәр хастаханәсе», Казан шәһәренең «2 нче шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләреннән күчереп «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Медицина-санитария частена эшкә кабул ителгән табиблар-белгечләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда Татарстан Республикасының дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренә эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары турында» 2014 ел, 25 февраль, 120 нче карарында күздә тотылган, алынган грантларга хокукын сакларга.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков